ШИМБӘ
20
МАРТ
1943 ел.
№ 63 (6785)
Аерым номеры 20 тиен.

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СССР СОВНАРКОМЫНДА һӘМ ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планы турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты түбәндәгеләрне әйтеп үтәләр:—сугыш вакытының авыр шартларында, тракторларның, атларның, транспорт средстволарының бер өлеше оборона кирәкләренә алынган булу, шулай ук авыл хуҗалыгыннан квалификацияле работникларның шактый өлешенең Кызыл Армиягә алынуы шартларында, колхозлар һәм совхозлар көзге һәм язгы чәчүне уңышлы үткәрделәр һәм төп азык культуралары—бөртекле ашлык, бәрәңге, яшелчә һәм шикәр чөгендере чәчүлекләрен шактый арттырдылар. 1942 нче елны көнчыгышта шикәр чөгендере, клещевина, махорка һәм башка төрле техник культуралар үстерү буенча яңа баштан зур базалар тудырылды.

Горький, Свердловск, Молотов, Москва, Иваново, Ярославль, Калинин, Тула, Рязань, Волгода өлкәләре, Чувашстан, Удмуртия АССР, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Грузия һәм Әрмәнстан ССР колхозлары һәм совхозлары кыр эшләрен яхшы итеп башкардылар. Бу өлкәләрнең һәм республикаларның колхозлары, МТС лары һәм совхозлары язгы чәчүне шактый кыска срокларда үткәрделәр, пар җирләрен вакытында сөрделәр һәм эшкәрттеләр, уҗым басуын киңәйттеләр һәм шактый зур мәйданнарны туңга сөрделәр. Бу өлкәләрдә һәм республикаларда дәүләткә ашлык, бәрәңге, яшелчә, җитен тапшыру планнары да шулай ук башка урыннарга караганда яхшырак үтәлә.

Колхозларда хезмәт дисциплинасы ныгыды, колхозчылар эш нормаларын яхшырак үтәделәр һәм хезмәт көннәренең мәҗбүри минимумын үтәмәүче колхозчылар саны шактый кимеде. 1942 нче елны колхозларда кыр эшләрендә җанлы тарту көченнән һәм ат инвентареннан яхшырак файдаланылды.

Шуның белән бергә, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты 1942 нче елны Пенза, Саратов, Куйбышев, Чкалов, Чиләбе, Омск, Кустанай һәм Төньяк Казахстан өлкәләрендә, Алтай краенда, Татарстан һәм Башкыртстан АССР да колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның төп авыл хуҗалыгы заданиеләрен үтәү буенча канәгатьләнерлек эшләмәгәнлекләрен күрсәтеп үтәләр. Бу өлкәләрдәге һәм республикалардагы күп колхозлар, МТС лар һәм совхозлар язгы һәм көзге культураларны чәчү буенча сан заданиесен үтәгән булсалар да, чәчү алдыннан эшкәртүнең сыйфатын түбәнәйткәннәр, чәчү срокларын озакка сузганнар һәм иген уңышын күтәрү өчен көрәш алып бармаганнар.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты барлык колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның, районнардагы, өлкәләрдәге, крайлардагы һәм республикалардагы совет, партия һәм җир органнарының игътибарын түбәндәгеләргә юнәлдерәләр:—1943 нче елны иген уңышын күтәрү һәм бөртекле ашлык һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары җыеп алуны арттыру өчен көрәштә төп игътибар кыр эшләренең сыйфатын күтәрүгә, язгы чәчүне кыска срокларда үткәрүгә, сөрүнең, чәчү алдыннан эшкәртүнең һәм чәчүнең сыйфатын яхшыртуга, җирле ашламаларның барлык төрләреннән тулысынча файдалануга һәм чүп үләннәренә каршы, авыл хуҗалыгы культуралары корткычларына каршы көрәш чараларын үткәрүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты 1943 нче елгы уңыш өчен барлык авыл хуҗалыгы культураларының чәчү мәйданын 1942 нче елны урып-җыелган мәйданга чагыштырганда 6,4 миллион гектарга, шул исәптән бөртекле культуралар буенча 1942 нче елга чагыштырганда 3,9 миллион гектарга артык итеп расладылар, шулай ук 1943 нче елга сабан культуралары чәчү планын, 1944 нче елгы уңыш өчен уҗым культуралары чәчү планын, бөртекле, техник культуралар һәм бәрәңге уңышы планын, МТС ларның трактор эшләре планын һәм агротехника чаралары планын расладылар.

1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планын үтәү максаты белән ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирделәр:

I. Колхозларны, МТС ларны һәм совхозларны язгы чәчүгә әзерләү турында

1. СССР ның Җир эшләре халык комиссариатын, СССР ның Совхозлар халык комиссариатын, СССР ның Азык промышленносте халык комиссариатын, СССР ның Ит-сөт промышленносте халык комиссариатын, Тышкы сәүдә халык комиссариатын, өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, союзный һәм автономияле республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкә һәм край комитетларын һәм союзный республикалар компартияләре Үзәк Комитетларын,—авыл хуҗалыгы эшләре планын 10 көн срок эчендә районнарга, совхозларга, МТС ларга, колхозларга һәм ялгыз хуҗалыкларга җиткерергә мәҗбүр итәргә.

2. Союзный һәм автономияле республикаларның совнаркомнарына, өлкә башкарма комитетларына, край башкарма комитетларына, партиянең өлкә һәм край комитетларына һәм союзный республикалар компартияләренең Үзәк Комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

а) бөртекле культуралар буенча шушы карарда билгеләнгән уртача уңыш нигезендә аерым бөртекле культураларның уңышы заданиеләрен, шулай ук күпме уңыш бирүләре бу карарда күрсәтелмәгән техник, яшелчә, бакча, терлек азыгы һәм җиләк-җимеш культуралары буенча уңыш заданиеләрен расларга;

б) парниклар һәм теплицалар салу һәм яңаларын төзү, агач утырту, тутчылык, җиләк-җимеш, виноград һәм эссе як үсемлекләре утырту, питомниклар ясау планын, шулай ук болыннарны һәм көтүлекләрне яхшырту чаралары планын расларга һәм аны районнарга һәм колхозларга җиткерергә;

в) сугарыла торган җирләрдән чәчү өчен тулысынча файдалануны тәэмин итеп, су сибелә торган җирләрдә чәчү мәйданнары һәм иген уңышы буенча районнар һәм колхозлар өчен заданиеләр билгеләргә

3. СССР ның Җир эшләре халык комиссариатын, СССР ның Совхозлар халык комиссариатын, өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, союзный һәм автономияле республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкә һәм край комитетларын, союзный республикалар компартияләре Үзәк Комитетларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) колхозларның производство планнарын, МТС ларның промфинпланнарын төзүне һәм МТС ларның колхозлар белән договорлар төзүен 10 көн срок эчендә тәэмин итәргә;

б) шул ук срок эчендә колхозларда администрация һәм хезмәт күрсәтү эшләрендә эшләүче колхозчылар санын минимумга кадәр кыскартып, производство бригадаларын һәм звеноларны тулыландыру, таралган урыннарда яңа бригадалар һәм звенолар оештыру эшләрен үткәрергә. Бригадаларга участоклар, инвентарь һәм тарту көче беркетелгәнлекне тикшерергә, тарту көчендә һәм авыл хуҗалыгы машиналарында эшләүдә иясезлекне бетерергә. Трактор һәм кырчылык бригадалары буенча язгы эш планнары төзергә һәм аларны расларга, аларда аерым эшләрне үткәрү срокларын, колхозчыларның, тракторларның һәм җанлы тарту көченең аерым кыр участокларына һәм эшләргә ничек урнаштырылуын күрсәтергә;

в) һәрбер бригадага, кагыйдә буларак, кимендә бер елга иң күбе өч-дүрт культура беркетелерлек итеп, техник, яшелчә культураларының, кукурузаның, бәрәңгенең һәм башка төрле сызма культураларның чәчү мәйданнарын звеноларга беркетүне тәэмин итәргә;

г) 1943 нче елга авыл хуҗалыгы һәм трактор эшләре планнарын үтәү буенча звеноларның, бригадаларның, колхозларның, МТС ларның, совхозларның һәм районнарның социалистик ярышын киң күләмдә оештырырга һәм кыр эшләре башлануга иң азы ике атна калганда аларның язгы чәчүгә әзерлекләрен үзара тикшерү эшен үткәрергә;

д) һәрбер колхозда, кыр эшләре башлануга аз дигәндә ун көн калганда, балалар ясләләре, балалар площадкалары, кыр станнары һәм җәмәгать туклануы оештыруны тәэмин итәргә, моның өчен кадрлар, биналар һәм җиһазлар билгеләргә һәм әзерләргә;

е) районнарның, колхозларның һәм совхозларның язгы чәчүгә әзерлек чараларын үтәүләренә системалы тикшерү үткәрергә. 1943 нче елның 30 нчы мартына район башкарма комитетларыннан отчетлар сорап алып, 1943 нче елның 5 нче апреленнән соңга калмыйча өлкәнең, крайның яки республиканың 1943 нче елгы язгы чәчүгә әзерлеге турында СССР Совнаркомына хәбәр итәргә.

4. «МТС ларның тракторларын, комбайннарын һәм авыл хуҗалыгы машиналарын 1943 нче елгы кыр эшләренә әзерләү турында» СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1943 нче ел 27 нче февраль карарының 15 нче статьясына өстәмә итеп, МТС ларның газогенераторлы СХТЗ тракторында эшләүче тракторчылары, әгәр дә алар үз сменаларында 15 календарь эш көнендә, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 30 гектар эшләсәләр, 35 хезмәт көне күләмендә премия алалар дип билгеләргә; шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук срок эчендә 30 гектардан артык эшләнгән һәрбер гектар өчен өстәмә рәвештә берәр хезмәт көне алалар.

Газогенераторлы көпчәкле СХТЗ тракторларында бер сменада эшләү нормаларын сыек ягулык белән эшли торган СХТЗ тракторлары өчен билгеләнгән нормалардан 25 процентка кимрәк итеп билгеләргә.

5. Республикаларның совнаркомнарына, край һәм өлкә башкарма комитетларына,—МТС ларның һәм совхозларның газогенераторлы тракторлары өчен аларга якын булган урман участокларыннан фондлар аерып бирергә тәкъдим итәргә.

6. СССР Совнаркомының 1941 нче елның 27 нче мартында чыгарган 701 нче номерлы карарларын үзгәртеп, 1943 нче елга тракторларның һәм комбайннарның ике ремонт арасында эшләү срокларын кыскартырга һәм тракторларга, комбайннарга, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауга отчисление нормаларын уртача 20 процентка арттырырга.

СССР Җир эшләре халык комиссариатына,—шушы үзгәрешләрне исәпкә алып, аерым өлкәләр, крайлар һәм республикалар буенча тракторларның һәм комбайннарның ике ремонт арасындагы дифференцияләштерелгән эш срокларын, шулай ук тракторларга, комбайннарга, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауга отчисление өчен күтәренке нормалар билгеләргә рөхсәт итәргә.

7. СССР Җир эшләре халык комиссариатын, СССР Совхозлар халык комиссариатын, республикаларның совнаркомнарын, край һәм өлкә башкарма комитетларын, союзный республикалар компартияләре Үзәк Комитетларын, ВКП(б) ның край һәм өлкә комитетларын, урыннардагы җир органнарын, МТС һәм совхоз директорларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) язгы кыр эшләре башлануга, җитмәгән заправка арбаларын әзерләргә һәм аларны ягулык мичкәләре, насослар һәм вак заправка инвентаре белән тәэмин итәргә. Тракторларга һәм тагылма машиналарга техник уход үткәрү өчен кирәкле инструментларны һәм башка әйберләрне әзерләргә һәм алар белән тракторларны һәм трактор бригадаларын тәэмин итәргә;

б) 1943 нче ел эчендә барлык МТС ларда һәм совхозларда тракторчыларның, комбайнчыларның һәм бригадирларның техник белемнәрен арттыру өчен аларның техник укуларын оештырырга;

в) язгы кыр эшләре башлануга МТС ларда, трактор бригадаларына техник хезмәт күрсәтү өчен, автомашиналарга һәм җанлы тарту көченә куелган күчмә мастерскойлар оештырырга, күчмә мастерскойларны кирәкле җиһазлар, инвентарь һәм җайланмалар белән тәэмин итәргә һәм аларны, 20 тракторга бер күчмә мастерской исәбеннән, участок механикларына беркетергә.

МТС ларга һәм колхозларга,—договорлар төзегән чакта күчмә мастерской өчен колхоздан ат билгеләүне күздә тотарга киңәш бирергә.

8. Трактор бригадаларында, тракторчылар һәм колхозлар көче белән, җирле материаллардан иң гади мастерскойлар—тракторларга техник уход үткәрү өчен өсте ябулы урыннар салу буенча һәм бригадада ягулыкны саклау өчен иң гади кыр базлары ясау буенча трактор бригадаларының һәм колхозларның, алдынгы МТС ларның инициативасын яхшы дип табарга.

СССР Җир эшләре халык комиссариатына, республикаларның совнаркомнарына, край һәм өлкә башкарма комитетларына, союзный республикалар компартияләре Үзәк Комитетларына, ВКП(б) ның край һәм өлкә комитетларына, урыннардагы җир органнарына һәм МТС директорларына,—1943 нче елны иң гади мастерскойлар—өсте ябулы урыннар ясау һәм трактор бригадаларында иң гади кыр базлары ясау эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

9. Республикаларның совнаркомнарына, край һәм өлкә башкарма комитетларына, союзный республикалар компартияләре Үзәк Комитетларына, ВКП(б) ның край һәм өлкә комитетларына,—чәчүлекләрне тәрбияләп тору һәм игеннәрне урып-җыю өчен җирле промышленность предприятиеләрендә кирәк кадәр санда кул белән эшли торган авыл хуҗалыгы инвентаре (кәйләләр, казгычлар, сәнәкләр,ураклар һ. б.) эшләп чыгаруны оештырырга тәкъдим итәргә.

10. СССР Дәүләт банкысын,—башка хисаплар буенча банк белән расчетларның нинди хәлдә булуына карамастан, язгы кыр эшләренә ягулык китерү өчен совхозларга 1943 нче елның 1 нче июненә кадәр булган срок белән кредит бирергә мәҗбүр итәргә.

11. Совхозларның директорларына, совхоз территориясендә торучы хезмәткә яраклы булган бөтен халыкны һәм 14 яшьтән башлап яшь үсмерләрне мәҗбүри тәртиптә совхозларда авыл хуҗалыгы эшләрен үтәүгә тарту хокукын бирергә.

Көнлек эш нормаларын үтәгән өчен тракторчыларга натуралата премия бирү буенча СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче елның 22 нче сентябрендә чыгарган 1570 нче номерлы карарының 14 нче статьясында әйтелгән шартларны язгы кыр эшләре чорына СССР ның Совхозлар халык комиссариаты, СССР ның Азык промышленносте халык комиссариаты һәм СССР ның Ит-сөт промышленносте халык комиссариаты совхозларына да җәелдерергә.

12. 1943 нче елның 1 нче апреленнән башлап, СССР Совнаркомының рөхсәтеннән башка, совхозларга һәм МТС ларга ягулык китерүдән тыш, шулай ук әчкәре пунктлардан ашлык ташудан тыш, транспорт эшләрендә һәм башка эшләрдә тракторлардан файдалануны тыярга.

13. Колхозларның атларына бары тик Дәүләт Оборона Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарлары нигезендә генә мобилизация ясарга мөмкин дип билгеләргә.

14. Колхозларда бер эш аты белән яки ике үгез белән язгы кыр эшләре чорында кимендә түбәндәге күләмнәрдә җир эшкәртелергә тиеш дип билгеләргә (сөрүгә күчереп исәпләп, барлык язгы кыр эшләре):

10 гектар—Алтай, Хабаровск, Ставрополь һәм Краснодар крайларында, Кемерово, Курган, Новосибирск, Омск, Чиләбе,

(Дәвамы 2 нче биттә)

СССР СОВНАРКОМЫНДА ҺƏМ ВКП(б) ҮЗƏК КОМИТЕТЫНДА

1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дəүлəт планы турында

(ДƏВАМЫ)

Чкалов, Куйбышев, Ульяновск, Саратов, Тамбов, Пенза, Ростов, Сталинград, Воронеж, Курск, Орел, Тула, Рязань өлкəлəрендə, Башкыртстан, Татарстан, Калмык һəм Мордовия АССР ларда;

9 гектар—Казахстан ССР да, Бурят-Монголия АССР да, Горький, Иваново, Ярославль өлкəлəрендə һəм Красноярск краенда;

8 гектар—Киров, Молотов, Москва, Смоленск, Калинин, Ленинград өлкəлəрендə, Удмуртия, Кабардино-Балкария һəм Мари АССР ларда;

7 гектар—Чита, Иркутск, өлкəлəрендə һəм Приморье краенда;

6 гектар—Архангельск, Вологда, Свердловск өлкəлəрендə, Чувашстан АССР да, Үзбəкстан, Таҗикстан, Төрекмəнстан, Кыргызстан ССР ларда;

5 гектар — Якутия, Коми, Дагстан, Төньяк Осетия, Чечен-Ингушия АССР ларда, Карел-Фин, Грузия, Əрмəнстан һəм Азербайҗан ССР ларда.

15. Союзный һəм автономияле республикаларның совнаркомнарын, хезмəт иялəре депутатларының край һəм өлкə башкарма комитетларын түбəндəгелəргə мəҗбүр итəргə:

а) эчке хуҗалык эшлəрендə атлардан һəм үгезлəрдəн файдалануны киметеп, кыр эшлəрендə колхозларның һəм совхозларның җанлы тарту көчлəреннəн тулысынча файдалануны тəэмин итəргə;

б) кыр эшлəренең күлəменə, тарту көче белəн тəэмин ителүгə һəм язгы эшлəрнең билгелəнгəн срокларына карап, язгы кыр эшлəре чорында һəрбер районга бер ат белəн яки ике үгез белəн эшлəү нормаларын җиткерергə;

в) колхозлардагы һəм совхозлардагы эш терлеклəрен язгы кыр эшлəре чорына кирəк кадəр печəн белəн, концентрат һəм башка төрле азыклар белəн тəэмин итү өчен чаралар күрергə;

г) атларны һəм үгезлəрне кыр эшлəре башлануга иң азы өч атна калганда яхшы ашатуга һəм ялга куеп, колхозларны һəм совхозларны язгы чəчүдəн иң азы бер ай алда ат белəн эшлəү йөклəмəсен үтəүдəн азат итəргə;

д) язгы кыр эшлəрен нормаль срокларда үтəү өчен, һəрбер колхозга күпме тарту көче кирəклекне исəпкə алып, җəмəгать көтүлəре һəм колхозчыларның үз файдалануларында булган сыерлар исəбенə колхозларның кыр һəм транспорт эшлəренə аз продукт бирə торган сыерларны тарту буенча районнарга карата план расларга. Район башкарма комитетлары кыр эшлəрендə сыерлардан файдалану планын, җəмəгать терлеклəре исəбенə аерым рəвештə һəм колхозчылар сыерлары исəбенə аерым рəвештə, һəрбер колхозга җиткерергə тиешлəр.

16. Сыерларны сайлап алу һəм алардан кыр эшлəрендə файдалану өчен җаваплылыкны колхозларның председательлəренə, районнардагы һəм колхозлардагы зоотехника һəм ветеринария работникларына йөклəргə. Язгы кыр эшлəре вакытына җəмəгать терлеклəреннəн аерып бирелгəн сыерларны кырчылык бригадаларына, бригадирның үз җаваплылыгына тапшырырга. Кырчылык бригадаларына бирелгəн барлык сыерларга хезмəт күрсəтү һəм алар белəн эшлəү өчен аларны бу бригадалардагы колхозчыларга, шулай ук сөт савучыларга язгы кыр эшлəре бетү вакытына кадəр беркетергə, сыерларны тəрбиялəүдə һəм алардан эштə файдалануда иясезлек булуга һичбер хəлдə дə юл куймаска. Колхозчылардан алынган сыерлар белəн, кагыйдə буларак, бу сыерларның хуҗалары булган колхозчылар үзлəре эшлəргə тиеш дип билгелəргə. Сыерлардан җиңелрəк эшлəрдə һəм якынрак араларда файдаланырга киңəш бирергə. Сыерлар белəн эшлəгəндə йомшак җигү əйберлəре генə кулланырга. Нəселле сыерларны кыр эшлəренə тартуны тыярга.

17. Колхоз правлениелəренə түбəндəгелəрне киңəш итəргə:

а) колхозда сыерлар белəн эшлəүче колхозчылар өчен эш нормаларын колхозда шундый ук эшлəрне ат белəн эшлəүгə билгелəнгəн нормаларның өчтəн бер өлеше күлəмендə итеп билгелəргə, лəкин эш башыннан эшлəү бəялəрен киметмəскə. Колхозда үз сыерлары белəн эшлəүче колхозчыларга, əгəр дə алар эш нормасын үтəсəлəр, ике өлеш хезмəт көннəре язарга;

б) колхозчылар сыерларының җəмəгать хуҗалыгында эшлəп үткəрəчəк барлык көннəренə колхозның җəмəгать терлеге өчен билгелəнгəн нормалар буенча фураж бирергə.

18. СССР Җир эшлəре халык комиссариатын, СССР Совхозлар халык комиссариатын, өлкə һəм край башкарма комитетларын, союзный һəм автономияле республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкə һəм край комитетларын, союзный республикалар компартиялəре Үзəк Комитетларын түбəндəгелəргə мəҗбүр итəргə:

а) 1943 нче елгы язгы чəчү өчен барлык чəчүлек орлыкларын—бөртекле, техник культуралар, бəрəңге һəм терлек азыгы культуралары орлыкларын 1943 нче елның 1 нче апреленнəн соңга калмыйча тулысынча туплап бетерүне тəэмин итəргə, аларның сыйфатына һəм саклануына бик нык һəм системалы контроль куярга, шулай ук яшелчə культуралары орлыклары əзерлəүне һəм салуны тəэмин итəргə; дəүлəткə тапшырылырга тиешле булган бөртекле культуралар һəм майлы культуралар орлыклары исəбенə чəчүлек орлык салуга юл куймаска;

б) тишелеп чыгышы начар булган орлыкларны, тиешенчə өстəмə түлəү белəн, колхозлар арасында яхшы сыйфатлы орлыкларга алмаштыруны оештырырга;

в) һəрбер колхозда барлык орлык фондларын кладовщикның махсус акт буенча кабул итеп алуын тəэмин итəргə. Бу актта һəрбер культура буенча орлык фондларының саны һəм сыйфаты, шулай ук аларның сортлары күрсəтелгəн булырга тиеш;

г) 1942 нче елны бурычка алып торган орлыклар буенча колхозлар арасында исəп өзүне тəэмин итəргə; башка колхозлардан көтəчəккə орлык алып торган колхозларны бу орлыкларны үзлəренең дəүлəт каршындагы йөклəмəлəрен үтəгəннəн соң бик тизлек белəн кайтарып бирергə яки ике арада булган килешү буенча акчалата һəм башка авыл хуҗалыгы продуктлары белəн түлəргə мəҗбүр итəргə.

д) 1943 нче елны, ирекле нигезлəрдə, колхозлар арасында чəчүлек орлыклар белəн үзара ярдəм итешүне оештырырга, үзара ярдəм тəртибендə орлык алган колхозлар бурычка алынган орлыкларны 1943 нче елгы уңыштан кайтарачаклары турында язма обязательство бирергə тиешлəр дип билгелəргə. Бу обязательстволар буенча колхозлар бурычка бирелгəн орлыкларны дəүлəт каршындагы йөклəмəлəрне үтəгəннəн соң колхозда калган уңыштан һичбер бəхəссез түлəтергə хокуклы дип билгелəргə;

е) Хəзерлəүлəр халык комиссариатына,—башка колхозларга сату һəм бурычка бирү өчен аерып куелган орлыкларны бер əзерлəү пунктында колхозлардан кабул итəргə һəм башка пунктларда аларны колхозларга бирергə рөхсəт итəргə;

ж) колхозларда һəм совхозларда орлык фондларының торышын һəм аларның саклану шартларын тоташтан тикшерүне үткəрүне тəэмин итəргə, табылган кимчелеклəрне бик тизлек белəн бетерергə һəм орлык фондларын бозуда һəм хуҗалыксыз саклауда гаепле булган кешелəрне суд җаваплылыгына тартырга;

з) бөртекле, бөртекле-кузаклы, техник культуралар һəм үлəн орлыкларын 1943 нче елның 10 нчы апрелена тулысынча чистартырга, сортларга һəм билгелəнгəн стандартларга кадəр китереп җиткерергə, моның өчен һəрбер колхозда кирəк кадəр санда орлык чистарту машиналары булдырырга һəм МТС ларның, Госсортфондның, Заготзерноның һəм башка оешмаларның орлык чистарта торган катлаулы машиналарыннан тулысынча файдаланырга, аларда ике смена белəн эшлəргə;

и) агулау өчен тикшерелгəн алыштыргычлардан файдаланып, бодай, арпа, солы, тары, җитен һəм мамык орлыкларын агулауны вакытында һəм тулысынча тəмам итəргə;

к) колхозларда һəм совхозларда орлыкларның тишелеп чыгулары, дымлылыклары, чүплəнүлəре, авырулар һəм корткычлар белəн зарарланулары ни дəрəҗəдə икəнлекне тикшерергə;

л) əгəр дə тишелеп чыгышлары ягыннан кондицияле булмаган орлыклар яшəүчəн булсалар, аларны яз башында ук җилгəрергə, академик Лысенко методы буенча юка катлау итеп салып һавада җылытырга һəм соңыннан аларның тишелеп чыгышын контроль-орлыкчылык лабораториялəрендə тикшерергə;

м) дымлылыгы күтəренке орлыклары булган колхозларда аларны орлык киптерү урыннарында һəм шуның өчен яраклаyдырылган биналарда, киптерү режимын бик нык саклап, киптерү эшен оештырырга;

н) 1943 нче елны чəчү өчен бөтен мəйданга җитəрлек орлыклык бəрəңге салуны тəэмин итəргə, əгəр орлык җитешмəсə, орлыклык бəрəңгене колхозлар колхозчылардан сатып алырга яки бурычка алып торырга тиешлəр. Колхозларны һəм совхозларны,—орлыклык бəрəңгенең, шулай ук əзерлəнгəн бəрəңге кисентелəренең саклануы шартларына һəм сыйфатына системалы тикшерү үткəрергə мəҗбүр итəргə;

о) Сортсемовощь конторалары тарафыннан контрактация ясалган яшелчə культуралары һəм терлек азыктамырлары орлыкларын əзерлəүне 1943 нче елның 1 нче апрелена тəмам итəргə;

п) чəчүлек орлыклык салу планын үтəмəгəн колхозларда, азык һəм фураж запасларыннан, 1943 нче елның язында орлык тамырлары чыгарып утырту буенча СССР Совнаркомы һəм ВКП(б) Үзəк Комитетының 1942 нче елның 19 нчы сентябрендə чыгарган 1562 нче номерлы карарында билгелəнгəн планның үтəлүен тəэмин итəрлек күлəмнəрдə өстəмə рəвештə орлыклык сайлап алырга һəм орлык тамырлары чыгарып утыртырга; салынган орлыклыкларны тулысынча сакларга; аларның əрəм-шəрəм ителүенə һəм саклаганда һəлак булуына юл куймаска.

19. СССР Җир эшлəре халык комиссариаты белəн берлектə, Хəзерлəүлəр халык комиссариатына өлкə башкарма комитетларының; край башкарма комитетларының һəм республикалар совнаркомнарының үтенече буенча, 1943 нче елның 15 нче апрелена кадəр булган вакыт эчендə, майлы культураларның гади орлыкларына алмашка һəм, гамəлдəге алмашу эквивалентлы буенча, азык культуралары орлыкларына алмашка дəүлəт ресурсларыннан майлы культураларның сортлы орлыкларын җибəрергə рөхсəт итəргə. Майлы культуралар орлыкларын барытик колхозлар һəм совхозлар тарафыннан алыштырыла торган орлыклар башта дəүлəтнең станция һəм пристань буендагы əзерлəү пунктларына тапшырылганнан соң гына бирергə.

20. Союзный һəм автономияле республикаларның совнаркомнарын, хезмəт иялəре депутатларының өлкə һəм край башкарма комитетларын,—яз башланганчы Сельхозснаб складларындагы, станция һəм пристань пунктларындагы бар кадəр минераль ашламаларны ташып бетерүне тəэмин итəргə мəҗбүр итəргə. Минераль ашламаларны беренче чиратта сугарыла торган җирлəрдə техник культуралар чəчелəчəк мəйданнарда файдаланырга.

21. Иген уңышын күтəрү эшендə тирестəн һəм башка җирле ашламалардан файдалануның аеруча əһəмияте барлыгын искə алып, союзный һəм автономияле республикаларның совнаркомнарын, өлкə, край һəм район башкарма комитетларын түбəндəгелəргə мəҗбүр итəргə:

а) җəмəгать терлеклəреннəн алынган тирестəн тулысынча файдалануны, аны беренче чиратта техник культуралар, бəрəңге һəм яшелчə культуралары җирлəренə, шулай ук уҗым чəчелəчəк пар җирлəренə кертүне күздə тотып, ашлана торган мəйданның күлəмен күрсəтеп, һəрбер колхоз өчен 1943 нче елны җирле ашламалар кертү планын билгелəргə;

б) уҗым чəчүлеклəрен, шикəр чөгендере, мамык, күксагыз, киндер чəчүлеклəрен, яшелчə культуралары һəм бəрəңге чəчүлеклəрен җирле ашламалар белəн яз көне тукландыруны тəэмин итəргə;

в) һəрбер бригадада ашламалар җыю һəм ташу өчен даими колхозчылар билгелəп куярга, ашлама ташу буенча аларга көнлек заданиелəр билгелəргə, шулай ук аларга ашламалар ташу буенча бөтен вакытка эш атлары һəм үгезлəр беркетергə, ашламалар ташуда җəмəгать терлеге сыерларын һəм колхозчыларның үз файдалануларында булган сыерларны киң күлəмдə файдаланырга;

г) һəрбер колхозда ашлама өчен, фекаль кəл, кош тизəге, черемə җыюны, шулай ук тиресне һəм башка ашламаларны дөрес саклауны тəэмин итəргə. Шəһəрлəрдə промышленностьта һəм көнкүрештə була торган ташландыкларны ашлама итеп файдалануны оештырырга, бу ашламаларны ташу өчен колхозларга һəм совхозларга шəһəр транспорты белəн ярдəм күрсəтергə;

д) торф чыга торган урыннарга якын булган колхозларда һəм совхозларда торфны тирес белəн, тирес суы белəн, фекаль белəн һəм башка төрле ташландыклар белəн катыштыруны, шулай ук терлеклəр астына салу өчен торфтан киң күлəмдə файдалануны оештырырга;

е) бактерияле ашламалардан тулысынча һəм дөрес файдалануны тəэмин итəргə, аларны кырга чыгару буенча колхозларга конкрет заданиелəр билгелəргə.

22. Колхоз правлениелəренə түбəндəгелəрне киңəш итəргə:

а) иң күп тирес җыюны һəм бөтен җыелган тиресне дөрес саклауны һəм вакытында басуга чыгаруны тəэмин иткəн терлекчелек фермасы мөдиренə һəм өлкəн ат караучыга, кызыксындыру төсендə, бер тапкыр 10 хезмəт көненнəн алып 30 га кадəр хезмəт көне язарга. Бу хезмəт көннəрен тирес басуга чыгарылып беткəннəн соң бирергə;

б) саламны һəм торфны терлеклəр астына салу өчен бирергə һəм җəмəгать кирəклəренə тирес бирүче колхозчыларга тирес ташу һəм терлек астына салына торган саламны һəм торфны ташу өчен транспорт бирергə.

23. Үзлəрендə чəчү əйлəнешлəре билгелəнеп тə, хəзергə əле алар үзлəштерелмəгəн колхозларга, культураларны үзлəреннəн алдагы культуралар артыннан дөрес урнаштыруны тəэмин итеп, 1943 нче елга чəчү заданиелəре нигезендə чəчү əйлəнешлəренə күчү планнарын ачыкландырырга тəкъдим итəргə. Чəчү əйлəнешлəре кертелмəгəн колхозларда 1943 нче елгы чəчү заданиелəрен культуралардан элек булган үсемлеклəрдəн яхшырак файдалануны исəпкə алу юлы белəн урнаштырырга.

24. СССР Наркомземын, СССР Наркомсовхозын, союзный һəм автономияле республикаларның совнаркомнарын, хезмəт иялəре депутатларының өлкə һəм край башкарма комитетларын, авыл хуҗалыгы культуралары корткычларына каршы көрəш чаралары планын билгелəргə мəҗбүр итəргə; черепашкага, саранчаларга, шикəр чөгендере һəм мамык корткычларына, шулай ук тычкан төренлəге кимерүчелəргə каршы көрəшкə аеруча игътибар бирергə.

II. 1943 нче елгы язгы чəчүдə агротехника чаралары турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һəм ВКП(б) Үзəк Комитеты, 1943 нче елгы язгы кыр эшлəре чорында иң əһəмиятле талəп кыр эшлəренең югары сыйфатлы булуыннан һəм язгы чəчүне һəрбер культура өчен иң яхшы булган агротехник срокларда үткəрүдəн гыйбарəт булырга тиеш дип саныйлар. Моның өчен түбəндəгелəрне эшлəргə кирəк:

1. Язгы кыр эшлəре башланыр алдыннан һəрбер колхозда басуларны саламнан, сабактан, чүп үлəннəреннəн һəм камылдан чистартуны тəэмин итəргə, əгəр дə кирəк дип табылса, янгынга каршы чараларны үтəгəн хəлдə, камылны һəм чүп үлəннəрен яндырырга.

2. Яз башында туфракның өлгерүенə җентекле күзəтү оештырырга, кыр эшлəрен башлауны соңга калдыруга һич тə юл куймаска, бигрəк тə яз сөрүне башлауны кичектермəскə, бу соңгысы, туфракның нинди хəлдə булуына карап, күп кенə хəллəрдə башка кыр эшлəреннəн алдарак башланырга мөмкин.

Кыр эшлəрен (тырмалауны, сөрүне, культивациялəүне, чəчүне), бөтен җирнең өлгереп җитүен көтеп тормыйча, аерым участоклар кибə барган саен сайлап алып эшли башларга.

3. Туңга сөрелгəн җирне вакытында иртə тырмалауга аеруча игътибар бирергə, аны кантарларның өсте кипкəннəн соң 3—5 көннəн дə соңга калмыйча үткəрергə. Язгы сөрү белəн тырмалау арасында өзеклек булуга юл куймаска.

Колхозларга һəм МТС ларга, язгы кыр эшлəрен агрегат төсендə үткəрүне киң күлəмдə кулланырга (сөрү һəм тырмалау, туңга сөрелгəн җирне культивациялəү һəм тырмалау, чəчү һəм катоклау, туңга сөрелгəн җирне культивациялəү-тырмалау-чəчү; сөрү-тырмалау-чəчү), бу вакытта туфракны эшкəртүнең яхшы сыйфатлы бу-

(Дəвамы 3 нче биттə)

СССР СОВНАРКОМЫНДА ҺӘМ ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планы турында

(АХЫРЫ)

луына һәм орлыкларның яхшы күмелүенә аеруча игътибар бирергә.

Язгы кыр эшләрендә сөрү-чәчү агрегатларын бары тик кырны сөрер алдыннан лущить иткәннән соң 10—12 сантиметрга сөргәндә генә һәм туңга сөрелгән җирне тирән итмичә яңадан сөргәндә генә кулланырга.

4. Колхоз правлениеләренә,—колхозда барлык язгы кыр эшләренең, шул исәптән язгы сөрүнең дә ничә эш һәм ничә календарь көнендә үткәреләчәген исәпләргә киңәш бирергә,—иртә һәм соң чәчелә торган культураларны чәчү һәрбер колхоз шартларында мөмкин булган срокларның иң яхшыларында үткәрелергә, туфракта иң күп дым сакланып калырга һәм чәчүлекләр чиста булсын өчен чүп үләннәрен бик җентекләп юк итәргә кирәк.

Корылыклы һәм ярым корылыклы районнарда басуларның чүпләнүенә каршы көрәшү, туфракта дым туплау һәм аны саклап калу һәм чәчүне иң кыска срокларда үткәрү максаты белән, колхозларга, көньяк-көнчыгыштагы корылыклы районнарда кыр эшләре башланганнан соң беренче 7 көн эчендә, ә Уралдагы, Себердәге һәм Төньяк Казахстандагы ярым корылыклы районнарда—беренче 10 көн, эчендә исәп буенча нормаль тирәнлеккә сөрергә мөмкин булмаган барлык участокларны язгы кыр эшләренең беренче 3—5 көне эчендә 5 сантиметр чамасы тирәнлектә лущить итәргә яки йомшартырга киңәш бирергә.

Шушылай алдан лущить ителгән басуларда, әгәр дә алар тамыр җәя торган һәм тамырдан үрчи торган чүп-үләннәре белән чүпләнмәгән булсалар, ә бер еллык чүп үләннәре (солыча һәм башкалар) инде тишелеп чыккан булсалар, андый җирләрдә, балчык катлавын яхшылап әйләндереп һәм чи җирләр калдырмыйча, 10—12 сантиметр тирәнлектә сөрергә мөмкин һәм сөрү артыннан ук тырмалау үткәрергә кирәк.

Тамыр җәя торган һәм тамырдан үрчи торган чүп үләннәре (сарут, билчән һәм башкалар) баскан басуларны, гәрчә ул басулар дымны күмү максаты белән яз башында лущить ителгән булсалар да, яз көне нормаль тирәнлеккә сөрергә кирәк.

Тары чәчү өчен билгеләнгән басуларда, әгәр дә алар туңга сөрелмәгән булсалар, яз башында дымны каплау өчен лущить ителүдән тыш һәм кыр эшләре башланудан күп дигәндә 10—15 көн үткәч сөрелүдән тыш; чүп үләннәре тишелеп чыкканнан соң туфракны киптерми торган табанлы культиваторлар белән культивацияләргә кирәк.

5. Туфракны яз башында сөрер алдыннан дымны сакларлык һәм чүп үләннәренең тишелеп чыгуын тизләтерлек дәрәҗәдә лущить итүне яки йомшартуны тизрәк үткәрү өчен, республикаларның совнаркомнарына, край һәм өлкә башкарма комитетларына,—колхозларны, МТС ларны һәм совхозларны тракторга һәм атка җигелә торган, туфрак эшкәртә торган киң колачлы эш кораллары (лущильниклар, дисклы тырмалар, бодай сабаннары, драпачлар һ. б.) белән тәэмин итү чараларын күрергә тәкъдим итәргә.

Киң колачлы эш коралларына (драпачларга, тырмаларга һ. б.) ремонт ясау, аларны яңарту һәм яңаларын әзерләү буенча җирле промышленность предприятиеләренә, МТС ларга, МТМ нарга һәм колхоз алачыкларына конкрет заданиеләр билгеләргә.

6. Техник, яшелчә культуралары һәм бәрәңге өчен билгеләнгән мәйданнарда иртә срокларда тирән итеп сөрүне тәэмин итәргә.

7. СССР ның көньяк-көнчыгыш районнарында бөртекле культураларны, туфрак әзерләнеп беткәч ук, туңга сөргәннән соң да, шулай ук язгы сөрүдән соң да мөмкин кадәр иртә срокларда, тезмә чәчкечләр белән чәчүне тәэмин итәргә.

Себернең, Уралның ярым корылыклы районнарында һәм Казахстан ССР ның төньяк өлкәләрендә туңга сөрелгән җирләрдә апрель аенда дымны саклау өчен барлык чараларны күрергә, чәчү өчен билгеләнгән мәйданнарны мөмкин кадәр күбрәк сөрергә һәм тырмаларга, май аенда сөреләчәк участокларда дымны каплап калдырырга, ә сабан бодаен чәчүне апрельнең соңгы көннәреннән башларга,—аны һәрбер хуҗалыкта 15—20 нче майга тәмам итәргә. Бу районнарда солыны майның икенче декадасыннан чәчә башларга.

Казахстан ССР, Бурят-Монголия АССР совнаркомнарын, Себер һәм Урал өлкәләре һәм крайлары башкарма комитетларын, җирле тәҗрибәдән файдаланып, һәрбер район буенча чәчүне башлау срокларын дифференцияләштерергә мәҗбүр итәргә.

8. МТС директорларын һәм колхоз правлениеләрен,—чәчүдә МТС ларның һәм колхозларның барлык тезмә чәчкечләреннән тулысынча файдаланырга мәҗбүр итәргә. Әгәр дә МТС лар эшне башкара алмасалар һәм чәчүне озакка сузсалар, колхозларга, чәчүне тизләтү өчен, трактор белән чәчәргә билгеләнгән җирләрдә атка җигелә торган чәчү машиналарын кулланырга киңәш бирергә.

9. Чәчү нормаларына һәм эшнең сыйфатына ныклы контроль куярга, түбәнәйтелгән нормалар белән чәчүдә һәм орлыкларны начар күмдерүдә гаепле булган кешеләрне җавапка тартырга.

10. СССР ның көньяк-көнчыгышындагы колхозларга,—солы чәчүлекләрен бер кадәр кимету исәбенә, корылыклы районнарда аеруча күп уңыш бирә торган культура булган арпа чәчүлекләрен киңәйтергә киңәш бирергә.

11. Язгы чорда уҗым культураларын вакытында һәм яхшы тәрбияләүгә зур әһәмият биреп, урыннардагы совет һәм партия органнарын һәм колхоз правлениеләрен түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) уҗым культуралары чәчүлекләренең торышына җентекле күзәтү оештырырга. Әгәр дә чәчүлекләрнең чыланудан һәлак булулары куркынычы туса, андый участоклардан суны вакытында агызып җибәрүне тәэмин итәргә;

б) өскә калыккан чәчүлекләрдән һәм җиңел туфраклардагы чәчүлекләрдән тыш барлык уҗым культураларын тырмаларга;

в) уҗымнар өскә калыккан мәйданнарда аларны катокларга;

г) уҗым культураларын мөмкин кадәр иртә срокларда һәм беренче чиратта орлыклык участокларда, уҗым бодае чәчүлекләрендә һәм сирәкләнгән арыш чәчүлекләрендә җирле ашламалар (кош тизәге, тирес сыекчасы, көл, чермә һ. б.) белән тукландыруны кулланырга;

д) уҗым культураларын, беренче чиратта бодайны һәм сирәкләнгән арыш чәчүлекләрен, яз көне иртә утауны үткәрергә;

е) уҗым культураларын тәрбияләү чараларын колхозларның язгы чәчү буенча эш планнарына кертергә.

12. Әгәр дә уҗым культуралары һәлак була калсалар, аларны яз көне яңадан чәчү сабан культураларын чәчү буенча билгеләнгән планнан тыш үткәрелә дип билгеләргә.

Республикаларның совнаркомнарын, край һәм өлкә башкарма комитетларын, һәлак булган уҗым культураларын вакытында яңадан чәчү өчен чаралар күрергә мәҗбүр итәргә.

13. Күрше колхозлардагы һәм совхозлардагы файдаланылмый торган сөрү җирләрен эшкәртү исәбенә үзләренең чәчү мәйданнарын киңәйтергә теләүче колхозларның үтенечен игътибарга алып, өлкә башкарма комитетларына, край башкарма комитетларына, республикаларның совнаркомнарына һәм СССР Наркомсовхозына күрше колхозларның һәм совхозларның файдаланылмый торган сөрү җирләрен, аларның ризалыгы белән, сугыш вакытында, аерым колхозларга эшкәртү һәм чәчү өчен бирү хокукын бирергә. Чәчелә торган мәйданнан авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру буенча дәүләт каршындагы йөкләмәләрне үтәүне бу җирләргә чәчкән колхозларга йөкләргә.

III. Чүпләнгән җирләр урынына кысыр калган һәм яткын җирләрдән файдалану һәм СССР ның көнчыгыш районнарында чәчүлекләрне дөрес урнаштыру турында

1. Өлкә, край башкарма комитетларын, партиянең өлкә һәм край комитетларын,—кыр эшләре башланганчыга кадәр, районнар һәм совхозлар буенча, район башкарма комитетларын һәм партия райкомнарын—һәрбер колхоз буенча басуларда культураларның чиратлашуларын тикшереп белергә һәм 1943 нче елны язгы һәм көзге чәчүлекләрне 4—5 ел рәттән һәм аннан да күбрәк еллар буена бөртекле культураларны бөртекле культуралар артыннан чәчмәслек итеп урнаштырырга ирешергә, сабан бодаен үзеннән алдагы иң яхшы ашланган элгәрләрдән соң чәчүне һәм иң күп чүпләнгән җирләрне пар җире итеп һәм күп еллар эшләнми торган җир итеп калдыруны тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

2. Кысыр калган һәм яткын җирләре булган колхозларның правлениеләренә, совхозларның директорларына, 1943 нче елның языннан башлап бу җирләрдән сабан һәм уҗым культуралары чәчү өчен файдаланырга, аеруча күп сөрелгән һәм солыча белән, кырлык белән һәм тамыр җәя торган чүп үләннәре белән чүпләнгән җирләрнең бер өлешен кысыр һәм яткын җир итеп калдырырга тәкъдим итәргә.

3. Өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, партиянең өлкә һәм край комитетларын,—районнарда, МТС ларда, колхозларда һәм совхозларда булган тракторларны һәм җанлы тарту көчен исәпкә алып, 10 нчы апрельгә кадәр районнар һәм совхозлар буенча, ә район башкарма комитетларын һәм партия райкомнарын—колхозлар буенча 1943 нче елны һәм аерым рәвештә 1944 нче елны сабан һәм уҗым культуралары чәчелергә тиеш булган, әлегәчә кысыр калган җирләрнең һәм яткыннарның күләмнәрен билгеләргә, шулай ук районнар, совхозлар һәм колхозлар буенча күп тапкырлар сөрелгән һәм аеруча чүпләнгән, кысыр һәм яткын итеп калдырылырга тиеш булган җирләрнең күләмен билгеләргә мәҗбүр итәргә.

4. МТС директорларын, колхозлар белән договорлар төзегән чакта МТС ларның трактор эшләре планына кысыр җирләрне һәм яткыннарны өлкәләрдә һәм крайларда билгеләнгән планга туры китереп тракторлар белән эшкәртүне кертергә һәм бу эшкәртүне тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

5. МТС директорлары, район җир бүлекләре мөдирләре, район җир бүрекләренең баш агрономнары, МТС ларның өлкән һәм участок агрономнары, кысыр җирләрне һәм яткыннарны эшкәртү буенча һәм аларга 1943 нче елны сабан һәм уҗым культуралары чәчү буенча билгеләнгән планнарны, яхшы эш сыйфаты белән үтәгән һәм арттырып үтәгән өчен СССР Наркомземыннан бер айлык хезмәт хакы күләмендә премия алалар дип билгеләргә.

6. СССР Наркомземын, Алтай һәм Красноярск край башкарма комитетларын, Кемерово, Новосибирск, Омск, Курган, Чиләбе өлкә башкарма комитетларын һәм Казахстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре башкарма комитетларын,—колхозларга булышлык күрсәтү һәм 1943 нче елны сабан һәм уҗым культуралары чәчүдә колхоз кырларында культураларны дөрес урнаштыру өчен 1 нче апрельдән 10 нчы майга кадәр агрономнарны тартырга һәм аларның һәрберсенә 4—6 колхоз беркетергә мәҗбүр итәргә.

7. СССР Наркомземын, СССР Наркомсовхозын, өлкә һәм край башкарма комитетларын, партиянең өлкә һәм край комитетларын, 1943 нче елны басуларда культураларны урнаштырган чакта чәчү әйләнешләрендә культураларның билгеләнгән чиратлашулары бозылуга юл куймау өчен чаралар күрергә мәҗбүр итәргә. Үзләрендә инде кисеп куелган чәчү әйләнешләре булган колхозларда һәм совхозларда кысыр һәм яткын җирләр булса чәчү әйләнешендә кысыр басу булсын өчен өстәмә рәвештә 2—3 басу кисеп куярга рөхсәт итәргә.

8. Өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, район башкарма комитетларын, партиянең өлкә, край һәм район комитетларын, — хезмәткә яраклы күпме кеше, күпме тарту көче барлыкка, терлекчелекне үстерү планына туры китереп, шулай ук кертелгән чәчү әйләнешләрен исәпкә алып, колхозларга һәм районнарга чәчү мәйданнары буенча задание билгеләргә мәҗбүр итәргә, хезмәткә яраклы колхозчыларга һәм тарту көчләренә чиктән тыш зур нагрузка бирелгән аерым районнар һәм колхозлар буенча, кирәк булган хәлләрдә, чәчү заданиеләрен киметүгә юл куярга, ләкин гомумән алганда өлкә һәм край буенча бөтен чәчү мәйданының күләме 1943 нче елга билгеләнгән чәчү планы дәрәҗәсендә сакланып калырга тиеш.

9. Өлкә башкарма комитетларына, край башкарма комитетларына, партиянең өлкә һәм край комитетларына, — районнар һәм колхозлар буенча аеруча тиз өлгерешле һәм күп уңыш бирә торган шепкән (рыжик) чәчүлекләрен, ә корылыклы һәм ярым корылыклы районнарда арпа чәчүлекләрен киңәйтү плачнарын билгеләргә тәкъдим итәргә. Колхозларга һәм совхозларга, — сабан бодаеның ике төрле сортын — аеруча иртә һәм аеруча соң өлгерә торган төрләрен чәчәргә киңәш бирергә.

10. Колхозларда һәм совхозларда күп елларга кысыр һәм яткын итеп калдырылган, чүпләнгән җирләр белән янәшә булган басуларның чүпләнүенә юл куймас өчен колхозларның председательләрен һәм совхозларның директорларын бу басуларда чүп үләннәрен чәчәк атканчыга кадәр чабып алырга мәҗбүр итәргә.

11. СССР Наркомземын, Алтай һәм Красноярск крайлары башкарма комитетларын, Кемерово, Новосибирск, Омск, Курган, һәм Чиләбе өлкә башкама комитетларын һәм Казахстан ССР Совнаркомын, 1943 нче елның 10 нчы апрелена кадәр, өлкәләрдә, крайларда һәм республикаларда булган җир төзүчеләр кадрларын һәм планга кертелгән җир төзү материалларын исәпкә алып, колхозларда 1943 нче елга чәчү әйләнешләре кертү планын расларга мәҗбүр итәргә.

12. СССР Наркомсовхозын,—Көнчыгыш районнардагы барлык совхозларда чәчү әйләнешләре кертүне 1943—1944 нче елларда тәмам итәргә, моның өчен СССР Наркомсовхозы системасында булган җир төзүчеләрне шушы ике елга СССР ның көнчыгыш районнарындагы совхозларда чәчү әйләнешләре кертү эшенә күчерергә мәҗбүр итәргә.

13. СССР ның әле чәчү әйләнешләре кертелмәгән көнчыгыш районнарындагы күп колхозларда һәм совхозларда кысыр һәм яткын җирләрнең күплеген исәпкә алып, СССР Наркомземына һәм СССР Наркомсовхозына мондый колхозларда һәм совхозларда чәчү әйләнешләре кертүне тизләтергә тәкъдим итәргә, культураларны дөрес урнаштыру өчен чәчү әйләнешендә кысыр һәм яткын җирләрдән файдаланырга.

* * *

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты, урыннардагы совет һәм партия органнарына 1942 нче елны булган зарарлы практиканы,—ягъни авыл хуҗалыгы эшләрен үткәргәндә конкрет шартларны һәм җирле тәҗрибәне, шулай ук агрономия персоналының күрсәтмәләрен игътибарга алмау практикасын бетерү турында кисәтү ясарга кирәк дип саныйлар һәм, дөрес агротехник чараларны һәм һәрбер колхозның конкрет шартларында иң күп авыл хуҗалыгы культуралары алуны тәэмин итәрлек методларны сайлап алуда һәм үткәрүдә колхозчыларның һәм агрономия работникларының инициативасы һәм җаваплылыгы сугыш шартларында аеруча әһәмияле икәнлеккә игътибарны юнәлдерәләр.

СОВЕТ ИНФОРОМБЮРОСЫННАН

19 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

19 нчы мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

• • •

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр район үзәге һәм тимер юл станциясе Издешковоны алганнан соң сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган тагын берничә пунктны азат иттеләр. Н-че берләшмә частьлары, Днепрның көнбатыш ярында һөҗүмне җәелдереп, немецлар пехотасының контратакасын кире кайтардылар, дошманны алып ташладылар һәм 300 гә якын гитлерчыны юк иттеләр.

• • •

Чугуево районында бик каты сугышлар дәвам итте. Дошман пехота һәм танкларның яңа көчләрен китерде һәм безнең позицияләргә атака ясады. Н-че часть сугышчылары, гитлерчыларның атакаларын кире кайтарып, немецларның 5 танкысын җимерделәр һәм 400 гә якын солдат һәм офицерларын юк иттеләр. Сугыш нәтиҗәсендә тик бер генә участокта дошман танклары безнең подразделениеләрне беркадәр кысрыклый алдылар.

Безнең авиация дошманның пехотасы һәм йөкләре төялгән 100 гә якын автомашинасын юк итте яки зарарлады һәм һава сугышында немецларның 3 самолетын атып төшерде.

• • •

Ильмень күленнән көньяктарак безнең частьлар, дошманның бик каты каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бик каты ныгытылган бу терәк пунктлар өчен булган сугышларда немецлар, үтерелгән хәлдә генә дә, 800 гә якын солдат һәм офицерларын югалттылар. Безнең сугышчылар немецларның 5 танкысын, 10 орудиесен, 22 пулеметын, бер сугыш припаслары складын һәм бер инженерлык милекләре складын кулга төшерделәр.

Безнең очучылар һава сугышларында дошманның 6 самолетын атып төшерделәр. Немецларның бер самолеты экипажы, парашютларда сикереп төшеп, качып китәргә маташкан иде, ләкин колхозчылар тарафыннан тотылды һәм совет часте штабына китерелде.

• • •

Чернигов өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче отрядның партизаннары, 13 нче мартка каршы төндә засадада торып, немецларның 17 автомашинасын юк иткәннәр. Совет патриотлары 80 гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм 5 пулемет, берничә дистә автомат һәм винтовка, бер миномет һәм 8 мең патрон кулга төшергәннәр.

• • •

Түбәндә Курск өлкәсенең Козля авылында немец-фашист кабахәтләренең ерткычлыклары турында акт китерелә: «Немец оккупантлар барлык колхозчыларны таладылар, аларны ач һәм ялангач калдырдылар. Кире чигенүгә бераз гына вакыт калганда, якшәмбе көнне, гитлерчылар Козля — Льгов юлын чистарту өчен 42 колхозчыны куып китерделәр. Кич белән эш тәмам булганнан соң колхозчыларны өйләренә җибәрмәделәр, бәлки көчле конвой белән Поповый Яр авылына алып киттеләр. Анда фашист бандитлар аларны бик озак мыскылладылар, соңыннан атып үтерделәр, гәүдәләрен өеп куйдылар һәм карга күмделәр. Немецларны куып җибәргәннән соң, аларның гәүдәләре чыгарылды. Аларның һәрберсендә коточкыч газаплау һәм җәфалау эзләре күренеп тора: Колхзочы Семен Семиченконың уң кулына һәм бер ягына штык белән кадалган, иң башына һәм башына пуля белән атылган. Фашистлар колхозчы Павел Тетеркинның авызын каерып ташлаганнар һәм күкрәгенә автоматтан атканнар; колхозчы Иван Лиховның эченә пычак белән кадаганнар, сул кулының өч бармагын кисеп алганнар; Петр Чкаловның бөтен тәне кисәкләнеп беткән, башы пуля белән тишелгән.

Гитлерчыларның бу кабахәт җинаяте онытылмас. Безнең совет җиренә басып кергән барлык җан кыючы немецлар җәзага дучар ителерләр. Ике аяклы фашист ерткычларга җир йөзендә урын юк».

Актка газапланып үтерелүчеләрнең кардәшләреннән һәм семья членнарыннан кул куйдылар: Михаил Тетеркин, Егор Лихов, Феона Мамонтова, Татьяна Скрипкина, Дарья Карманова һәм башкалар.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: очучы истребитель лейтенант М. Карабанов. Ул Ленинград блокадасын өзүдә катнашты, дошманның 24 самолетын, шулардан 5 сен Синявтю янында бәреп төшерде. Лейтенант Карабанов Кызыл байрак ордены белән бүләкләнде.

ТАСС фотохроникасы.

19 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

19 нчы мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

18 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 70 тән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 15 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар һәм 5 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

• • •

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Безнең частьларга каршы сугышларда дошман зур югалтуларга дучар була. Плен алынган немец солдатларының һәм офицерларының әйтүләренә караганда, немецларның 185 нче пехота полкы соңгы көннәрдә үзенең кешеләр составының дүрттән өч өлешен югалткан. Издешководан көньяктарак немецлар, алдан хәзерләп куелган терәк пунктларга таянып, каршылык күрсәтәләр. Безнең частьлар дошман оборонасының бер чиген алган чакта 400 гә якын гитлерчыны кырып ташладылар. Трофейлар кулга төшерелде, шулар арасында 7 орудие һәм 2 сугыш припаслары склады бар.

* * *

Төньяк Донецның урта агымы районында безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм пехотасының зур көчләренә каршы бик каты сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары гитлерчыларның берничә атакасын кире кайтардылар һәм дошманның 14 танкысын, 3 бронемашинасын, 12 орудиесен һәм 600 дән артык солдат һәм офицерларын юк иттеләр. Немецлар өстәмә көчләр китереп, яңадан атака башладылар һәм безнең подразделениеләрне бер-аз кысрыкладылар. Совет сугышчыларының кискен контратакасы белән дошман яңадан алып ташланды. Икенче бер участокта сан ягыннан артык булган дошман көчләре, зур югалтулар исәбенә, бер аз алга китә алдылар һәм халык яши торган ике пунктны кулларына төшерделәр.

Һава сугышларында безнең очучылар бер көн эчендә немецларның 11 самолетын атып төшерделәр.

• • •

Ильмень күленнән көньяктарак каты сугышлар дәвам итте. Халык яши торган бер пункт районында безнең частьлар немецларның бер батальон полицейскийларын кырып ташладылар һәм аларның барлык коралларын кулга төшерделәр. Икенче бер участокта 200 гә якын гитлерчы юк ителде. Безнең сугышчылар 4 орудие һәм төрле сугыш милекләре тутырылган бер склад кулга төшерделәр. Совет очучылары һава сугышларында немецларның 7 самолетын бәреп төшерделәр.

• • •

Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немецларның җәза экспедициясенә каршы сугышта 100 дән артык немец фашист басып алучыларны юк иткән. Икенче бер отрядның партизаннары 10 нчы мартка каршы төндә дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә танклар, кораллар һәм гаскәрләр төялгән 28 вагон һәм платформа җимерелгән. Җимерек вагоннар астында калып һәм атыш вакытында 200 ләп гитлерчы үтерелгән һәм яраланган.

• • •

Түбәндә Смоленск өлкәсенең Серго-Ивановская поселогында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немец басып алучылар Серго-Ивановскаяга килеп керү белән үк безнең өчен һичбер түзәргә мөмкин булмаслык тормыш башланды. Гитлерчы бандитлар безнең поселокны пычраттылар һәм бөтен халыкны таладылар. Эшкә чыкмаган өчен Мария һәм Александра Гайдуковаларны фашистлар халык алдында суктырдылар. Немец офицерлары бу кабахәт җәзалауны карап көлеп тордылар. Кайберәүләр фотоаппаратлар белән килделәр һәм рәсемнәр төшереп тордылар. Совет кешеләренең дәрәҗәсен төшерү өчен гитлерчылар һәрбер кешене муеннарына номерлы биркалар тагып йөрергә мәҗбүр иттеләр. Биркасыз бусагадан да атларга ярамады. Алар ешкына халыкның бирка тагып йөриме икәнлеген тикшереп тордылар. Чигенер алдыннан фашист ерткычлар бөтен поселок буйлап йөреп, качу урыннарына һәм землянкаларга килеп керделәр һәм 14 яшьтән башлап барлык яшьләрне үзләре белән алып киттеләр. Бер көн эчендә генә дә алар 35 яшь үсмерне, йортларыннан һәм ата-аналарыннан аерып, ирексезләп Германиягә каторгага алып киттеләр». Актка Андрей Карцев, Елена Бобко, Иван Машинистов һәм Павел Игнатовлар кул куйды.

• • •

Сәланик районында Греция патриотлары немецларга эшләүче химия заводын сафтан чыгарганнар. Заводның җиһазлары бөтенләй яраксыз хәлгә китерелгән. Пирей шәһәреннән ерак түгел генә Греция партизаннары итальян солдатлары утырган бер поездны юлдан чыгарганнар. Бер группа кораллы греклар оккупантларның бер хәрби складына һөҗүм иткәннәр. Партизаннар, сакчыларны үтереп, коралларын һәм сугыш припасларын кулга төшергәннәр.

ТУГАННАРЧА ЯРДӘМ

МӨСЛИМ, 16 март. (Телефон буенча). Районның колхозчылары немец оккупантлардан азат ителгән районнардагы колхозларга ярдәмне көне-төне көчәйтәләр. «Кызыл Октябрь» колхозы членнары 20 баш сарык, 5 баш сыер, «Кызыл сабанчы» колхозы членнары (Таугилде авылы) 15 баш сарык, 5 баш сыер, «Ык буе» колхозы членнары 7 баш сарык, 5 баш дуңгыз, «Тугай» колхозы членнары 10 баш сарык бүләк иттеләр.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

АЛДЫНГЫЛАРДАН ҮРНӘК АЛЫГЫЗ!

КОЛХОЗЛАРНЫҢ ОРЛЫК ФОНДЫНА СОВЕТ ПАТРИОТЛАРЫ ВЗНОСЫ

22. Хикмиева Х. — Минзәлә районы, «Яңа юл» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—222 пот ашлык кертте.

33. Шәйхетдинев Г. — Минзәлә районы, «Яңа юл» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—73 пот ашлык кертте.

24. Абдуллина К.—Минзәлә районы, «Чәчкәле» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—65 пот ашлык кертте.

25. Нәбиуллин—Минзәлә районы, «Алга» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—61 пот ашлык кертте.

26. Хәбибуллин — Минзәлә районы, «Кызыл йолдыз» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—61 пот ашлык кертте.

27. Закиров Г.—Минзәлә районы, «Кызыл йолдыз» колхозы члены, Ватан сугышында катнашучы—61 пот ашлык кертте.

28. Кашапов—Минзәлә районы, «Алга» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—52 пот ашлык кертте.

29. Сабиров—Минзәлә районы, «Алга» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—52 пот ашлык кертте.

30. Габдерәфиков С.—Минзәлә районы, «Үрнәк» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—52 пот ашлык кертте.

31. Корбангалин — Минзәлә районы, «Кызыл йолдыз» колхозы председателе—50 пот ашлык кертте.

32. Шәһретдинов — Минзәлә районы, «Ык буе» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—45 пот ашлык кертте.

33. Чебаков Я.—Кызыл йолдыз районы, «Восход» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—43 пот ашлык һәм 24 пот бәрәңге кертте.

34. Әхметов Х. —Минзәлә районы, «Кызыл йолдыз» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—40 пот ашлык кертте.

35. Якупов—Минзәлә районы, «Үрнәк» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—36 пот ашлык кертте.

36. Яковлев Ф.—Кызыл йолдыз районы, «Восход» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы—30,5 пот ашлык һәм 30,5 пот бәрәңге кертте.

37. Королев Н. —Яңа Писмән районы, Крупская исемендәге колхозның члены — 30,5 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге кертте.

38. Максимова М. — Кызыл йолдыз районы, «Привет» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы — 30,5 пот ашлык һәм 55 пот бәрәңге кертте.

39. Әхмәтҗанова — Минзәлә районы, «Ык буе» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы, фронтовик хатыны — 30 пот ашлык кертте.

40. Кучукова А. — Яңа Писмән районы, «Политотделовец» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы — 24 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге кертте.

41. БайсаровЕ.— Кызыл йолдыз районы, «Восход» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы — 24 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге кертте.

42. Яныйна С. — Яңа Писмән районы, «Вязовка» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы — 21 пот ашлык һәм 18 пот бәрәңге кертте.

43. Вәлиуллин Р. — Арча районы, «Кызыл сәрдә» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы — 21 пот ашлык кертте.

44. Эюпов — Октябрь МТС ының трактор бригадасы бригадиры — 18 пот ашлык һәм 21 пот бәрәңге кертте.

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — **«Башмагым»**.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 21 нче мартта — **«Мәрьям»**.

Зур драма театры. Бүген—**«Нашествие»**.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген һәм 21 нче мартта Менжинский исемендәге клубта зур концерт. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

Яшь тамашачылар театры. Бүген кичке 7 сәгатьтә—«Москвичка».

«Электро». Яңа документаль фильм. **«Сталинград»**. «Унион». Көндез—**«Богдан Хмельницкий»**, кич — **«Иран»**. «Пионер». көндез—**«Вулкандагы вакыйга»**, кич — **«Минем мәхәббәтем»**. «Чаткы»—« Дубровский».

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 12103 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 510